**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналының атамасы үзгәрү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының бердәм норматив хокукый актлар банкы турында» 2002 елның 8 маендагы ПУ-352 номерлы Указының (Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 25 ноябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2005 елның 7 сентябрендәге ПУ-361 номерлы, 2007 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге ПУ-687 номерлы, 2013 елның 10 августындагы ПУ-751 номерлы һәм 2015 елның 6 мартындагы ПУ-247 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 6 пункты беренче абзацына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналында» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибе турында» 2004 елның 2 июнендәге ПУ-431 номерлы Указы (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 12 июлендәге ПУ-445 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-622 номерлы, 2014 елның 14 августындагы ПУ-788 номерлы һәм 2015 елның 20 февралендәге ПУ-178 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Президенты актларын әзерләү, бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү, Татарстан Республикасы законнары проектларын Татарстан Республикасы Президентына бирү тәртибенең 11 пункты икенче абзацына «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары

җыентыгы» журналында» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналында» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 08 июль
№ ПУ-585